СОВЕТ ПЕЧИЩИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ПЕЧИЩИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

22.10.2019 с. Печищи № 54-262

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге торак пунктларының исемнәрен бирү, урамнарны һәм башка состав өлешләрен үзгәртү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге Уставы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге Советы
Карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге торак пунктларының урам исемнәрен бирү, урам исемнәрен һәм башка состав өлешләрен үзгәртү тәртибе турында Нигезләмәне расларга (№1 Кушымта).
2. Әлеге карарны «Волжская новь» район газетасында бастырырга, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Бу карарның үтәлешен тикшереп торуны Печищи авыл җирлеге Советының законлылык, хокук тәртибе һәм регламент буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге Башлыгы Л.В. Яковлев

Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге Советының
22.10.2019 № ________ карарына
№1 Кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге торак пунктларының урам исемнәрен бирү, урам исемнәрен һәм башка состав өлешләрен үзгәртү тәртибе турында
Нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге торак пунктларының урам исемнәрен бирү, урам исемнәрен һәм башка состав өлешләрен үзгәртү тәртибе турындагы әлеге Нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге Уставы нигезендә эшләнгән һәм Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге торак пунктларының урам исемнәрен бирү, урам исемнәрен һәм башка состав өлешләрен үзгәртүнең бердәм тәртибен тәэмин итү хокукый нигезләрен билгели.

1.2. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге торак пунктларының урам исемнәрен бирү, урам исемнәрен һәм башка состав өлешләрен үзгәртү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» карар Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге Советы тарафыннан кабул ителә.

1.3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге урамнарына һәм башка состав өлешләренә кагылышлы төп таләпләр:

- территориянең тиешле өлешендә географик, тарихи, шәһәр төзелеше һәм башка үзенчәлекләргә туры килергә тиеш;
- урамның һәм башка состав өлешләренең иң әһәмиятле шәхси характеристикаларын күрсәтергә;
- аваздаш һәм әйтү өчен уңайлы булырга тиеш;
- Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә хокукый язылышының һәм әйтелешләрнең әдәби нормаларына туры килергә;
- яңа исемнәр гамәлдәге атамаларны кабатларга тиеш түгел.

1.4. Исемнәрне бирү Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге торак пунктларының башка состав өлешләренә, шулай ук аларның исемнәрен үзгәртүгә бәйле урамнарда, мәйданнарда башкарыла.

1.5. Өстенлек Татарстан Республикасы халыкларының милли тарихын, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен чагылдыручы исемнәргә бирелә.

1.6. Кайбер атамаларны ирекле рәвештә алыштыру, ялган атамаларны куллану рөхсәт ителми.

2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге торак пунктларының урам исемнәрен бирү, урам исемнәрен һәм башка состав өлешләрен үзгәртү тәртибе

2.1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге торак пунктларының урам исемнәрен бирү, урам исемнәрен һәм башка

состав өлешләрен үзгәртү әлеге Нигезләмә нигезендә билгеләнгән тәртиптә түбәндәге тәкъдимнәр буенча гамәлгә ашырыла:

- дәүләт хакимияте органнары;
- җирле үзидарә органнары;
- дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр;
- иҗтимагый оешмалар;
- Печищи авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган Россия Федерациясе гражданнары. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге торак пунктларының урам исемнәрен бирү, урам исемнәрен һәм башка состав өлешләрен үзгәртү буенча гражданнарның инициативасы 30 (утыздан да ким булмаган) кешедән торган инициатив төркем төзү юлы белән тормышка ашырыла;
- Печищи авыл җирлеге территориясендә билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм үз эшчәнлекләрен алып баручы юридик затлар катнашында.

2.2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл авыл җирлеге торак пунктларының урам исемнәрен бирү, урам исемнәрен һәм башка состав өлешләрен үзгәртү турындагы тәкъдимнәр әлеге нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән затлар (алга таба - инициаторлар) тарафыннан Печищи авыл җирлеге Советына язма рәвештә кертелә.

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге торак пунктларының урам исемнәрен бирү, урам исемнәрен һәм башка состав өлешләрен үзгәртү турындагы тәкъдимнәр әлеге нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән затлар (алга таба-инициаторлар) тарафыннан Печищи авыл җирлеге Башлыгы исеменә язма рәвештә кертелә.

2.3. Исем бирү, исем алыштыру инициаторлары тарафыннан түбәндәге документлар тәкъдим ителә:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге торак пунктларының урамнарына исем бирү, исемен үзгәртү һәм башка состав өлешләрен үзгәртү турында үтенеч;
- тәкъдим ителә торган атаманы географик һәм тарихи-мәдәни нигезләү;
- күренекле кешеләр истәлеген мәңгеләштергәндә тасвирланган вакыйгаларны, аларның тормышы, эшчәнлеге турында биографик мәгълүматларны раслаучы документлар теркәлә һәм аларның хезмәтләре, шулай ук мирас хокукына ия гаилә һәм туганнарының ризалыгы күрсәтелә (алар булганда);
- әгәр үтенечнамә белән әлеге Нигезләмәнең №1 Кушымтасы нигезендә рәсмиләштерелгән инициатив төркем мөрәҗәгать иткән очракта, кул кую кәгазе.

Кул кую кәгазендә инициатив төркем әгъзалары үз фамилияләрен, исемен һәм атасының исемен, шәхесне раслаучы документ (шәхесне раслаучы документның сериясен, номерын), яшәү урыны адресын үз имзасын һәм аны кертү датасын шәхсән күрсәтәләр. Кул кую кәгазе имзалар җыю белән шөгыльләнүче инициатив төркем әгъзасы тарафыннан раслана.

2.4. Үтенечнамәдә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

- фаразланган исем;
- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге торак пунктларының урам һәм башка состав өлешләренең урнашуы билгеләнгән карта-схемасы;
- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге торак пунктларының урам һәм башка состав өлешләренең исемнәрен бирергә тәкъдим иткән инициаторлар турында мәгълүматлар, аларның адреслары, телефоннары.

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге торак пунктларының урамнарына һәм башка состав өлешләренә исем

биру тәртибе

3.1. Печищи авыл җирлеге торак пунктларының урам исемнәре һәм башка состав өлешләре белән килешеп, тәкъдимнәр карау нәтиҗәләре буенча, Печищи авыл җирлеге Советы Печищи авыл җирлеге торак пунктларының урамнарына һәм башка состав өлешләренә исем бирү турында Карар кабул итә.
3.2. Печищи авыл җирлеге торак пунктларының исемнәре һәм башка состав өлешләренә исем бирелү белән килешмәгән очракта, Печищи авыл җирлеге Советы Печищи авыл җирлеге торак пунктларының урамнарына һәм башка состав өлешләренә исем бирмәү турында Карар кабул итә, өч көнлек срокта Печищи авыл җирлеге торак пунктларының урамнарына һәм башка состав өлешләренә исем бирүдән баш тарту турында инициаторларга язмача хәбәр җибәрә

4. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге торак пунктларының урам исемнәрен
һәм башка состав өлешләрен үзгәртү тәртибе

4.1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге торак пунктларының урам һәм башка состав өлешләрен үзгәртү тәкъдиме белән, тәкъдимнәр кергән вакыттан ун көн эчендә, Печищи авыл җирлеге Башлыгы карары белән урамны, яки Печищи авыл җирлеге торак пунктларының башка состав өлешләрен үзгәртү буенча халык алдында тыңлаулар билгеләнә.
4.2. Печищи авыл җирлеге Башлыгы урам һәм башка состав өлешләрен үзгәртү белән килешмәгән очракта, өч көнлек срокта Печищи авыл җирлеге торак пунктларының урамнарына һәм башка состав өлешләренә исем бирүдән баш тарту турында язмача хәбәр юллый. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә чыгарыла, ул халыкка җиткерелергә тиеш.
4.3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге торак пунктларының исемнәрен үзгәртү турындагы Совет карары проекты раслау өчен Печищи авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан Печищи авыл җирлеге советына авыл халкының урам исемнәрен үзгәртү тәкъдиме белән авыл җирлеге Советына юллана. Печищи авыл җирлеге Советы якындагы утырышта Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге торак пунктларының урам исемнәрен үзгәртү турында Карар кабул итә.
4.4. Печищи авыл җирлеге Башлыгы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге торак пунктларының урам исемнәрен үзгәртү тәкъдиме белән килешмәгән очракта, Печищи авыл җирлеге торак пунктлары урамнарының һәм башка состав өлешләренең исемнәрен үзгәртүнең максатка ярашлы булмауы турында Карар кабул итә һәм ун көнлек срокта бу баш тарту турында инициаторларга хәбәр итә.

5. Йомгаклау нигезләмәләре

5.1. Әлеге Нигезләмә белән җайга салынмаган мәсьәләләр гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнә.
5.2. Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге урам һәм башка состав өлешләрен язу Печищи авыл җирлеге Советы карарында билгеләнгәнчә катгый рәвештә башкарыла.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге
торак пунктларының урам исемнәрен
бирү, урам исемнәрен һәм башка
состав өлешләрен үзгәртү тәртибе
турындагы Нигезләмәгә

Кушымта №1

КУЛТАМГА

Без, түбәндә кул куйган гражданнарның инициатив төркеме әгъзалары, ________________________________урнашкан ________________________________ түбәндәге атаманы бирергә тәкъдим итәбез

| N | Фамилиясе, исеме, атасы исеме | Паспорт яки аны алыштыручы башка документ мәгълүматлары | Адрес | Имза | Дата |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |